# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы  авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы  авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «2020 елда Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- су насосы сатып алу;
- МТЗ -82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- ДПО гаражын ремонтлау;
- халыкның ял итү урыннарын төзекләндерү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК

тоту белән  килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 290 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 156 кеше. Халык җыенында катнашучылар   җыелган акчаларны балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыруга юнәлтү  тәкъдимен кирәкми диеп карар чыгарды.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 156 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- су насосы сатып алу;
- МТЗ -82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу;

- ДПО гаражын ремонтлау;
- халыкның ял итү урыннарын төзекләндерү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү.

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.

2.“2020 елда Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы бинасынын мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин